ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.03.2026 г.Лениногорск № 5

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск шәһәре территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 16 февралендәге 8 номерлы карарына (16.02.2023 ел, №8 редакциядә)үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 июлендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә (08.08.2024 ел редакциясе), Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы белән, Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск шәһәре территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 16 февралендәге 8 номерлы карарына (16.02.2023 ел, №8 редакциядә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Исемне түбәндәге редакциядә бирергә:

«Лениногорск шәһәрендә урнашкан, төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия автомобиль юлларында урнашкан гомуми кулланылыштагы парковкалардан тыш парковкалар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне раслау турында»;

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Лениногорск шәһәрендә урнашкан, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан гомуми кулланылыштагы парковкалардан тыш, парковкалар реестрын алып бару тәртибе турында кушымтадагы Положениене расларга.».

2.Лениногорск шәһәрендә урнашкан, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан гомуми кулланылыштагы

парковкалардан тыш, парковкалар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Нигезләмә Лениногорск шәһәрендә урнашкан, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан гомуми кулланылыштагы парковкалардан тыш, парковкалар реестрын алып бару тәртибен билгели (алга таба - җирле әһәмияттәге гомуми кулланылыштагы парковкалар реестры).».

3.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.А. Мөхәмәтшин

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72